# Каләм белән җиңдем дошманны

*(Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар язучыларының иҗатына багышланган искә алу кичәсе)*

*Кичәдә ике алып баручы язучыларның биографияләре белән таныштыра, укучы әдипләрнең шигырьләреннән, әсәрләреннән өзекләр укый. Алып баручылар язучыларның биографиясе белән таныштырган вакытта магнитофон аша Муса Җәлилнең «Сагыну» җыры салмак кына уйнатыла.*

**1 а.б.** Исәнмесез, хөрмәтле укучыларыбыз! Хәерле көн!

**2 а.б.** 2023 елда киң җәмәгатьчелек Бөек Җиңүнең 78 еллыгын билгеләп үтә. Җиңү көне! Бу сүз һәркайсыбыз өчен дә чиксез кадерле.

**Җиңү көне —**
**Халык тантанасы,**
**Яз төренгән янар комачка.**
**Җир чәчәкләр тезгән күкрәгенә,**
**Йөз балкытып карый кояшка.**

**1 а.б. Бер кайтырбыз диеп киткән юлдан**
**Китсәләр дә алар кайтмады.**
**Алар өчен бары җилләр генә**
**Ачып-ябып йөрде капканы.**

**Алар өчен янды ялгыз ана**
**Күз нурларын сирпеп еракка.**
**Тик ил өчен геройларча дигән**
**Хәбәр генә кайтты бу якка.**

**Хәбәр генә кайтты бу якларга**
**Ядкәр булып газиз анага.**
**Һәм ир даны кайтты югалмыйча**
**Мәңгелек ут булып янарга.**

**Валиев Рәсим башкаруында җыр “Солдатлар”**

**1 а.б.** Ил өчен авыр сынау көннәрендә халкыбыз бер йодрыкка тупланды. Безнең кичә Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар язучыларына багышлана. Кичәбезне башлыйбыз.

**2 а.б.** Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев Саратов губернасының (хәзерге Пенза өлкәсенең) Кузнецкий районы Татар Кынадысы авылында туа.

Егерменче еллар башында Кутуй Казанга килә һәм педагогия институтында укый. Шул ук вакытта үзенең беренче шигырьләре белән матбугатка чыга. 1935 елда «Тапшырылмаган хатлар» исемле атаклы повестен яза. Бу әсәр бик күп телләргә тәрҗемә ителде, Америкада, Европа илләрендә басылып чыкты.

**5кл Ашрапов Ранил** «Сагыну» нәсереннән өзек укый:

*(Өзек укыган арада магнитофон аша чишмә челтерәгән, кошлар сайраган тавышлар салмак кына ишетелә).*

«Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил!

Мин шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып сап-салкын су эчәм. Әмма, күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.

Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил!

Сине сагынган саен миндә көч-дәрт арта, рухым канатлана. Чит илдә йөреп мин ачык аңладым: совет кешесе өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул.

Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем.

Сагындым, бик сагындым сине, изге Туган ил».

**1 а.б.** Ә хәзер сүзне 5нче сыйныф укучысы **Закирова Алсуг**а бирәбез

**2 а.б.**Герой-шагыйрь Муса Мостафа улы Җәлилов Оренбург өлкәсе Мостафа авылында туа. 10-11 яшьләрендә үк шигырьләр яза башлый. Бөек Ватан сугышына кадәр бик күп лирик шигырьләр һәм поэмалар иҗат итә, «Алтынчәч», «Илдар» исемле либреттолар яза.

Талантлы шагыйрь Муса Җәлил сугыш башлану белән фронтка китә һәм анда фашист илбасарларга каршы батырларча сугыша. 1942 елда каты яраланган хәлдә фашистлар кулына эләгә. Концентрацион лагерьда һәм Берлинда әсирләр арасында яшерен эш алып баруы өчен Моабит төрмәсенә ябыла. 1944 елда фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелә. Муса Җәлил соңгы сулышына кадәр дошманга каршы көрәшен туктатмый.

**Закирова Гөлүсә башкаруында җыр "Салют, сиңа Муса Җәлил"**.

**2 а.б**. Күренекле татар шагыйре Фатих Кәрим Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында туа.

1924 елда ул Казанга килә. Шунда шигырь язу белән мавыга башлый. 1926-1927 елларда аның «Төнге урам баласы», «Урман» исемле шигырьләре басыла. 1931 елда «Башлангыч җыр» исемле шигырьләр җыентыгы чыга. Кыска гына иҗат дәверендә Ф.Кәрим күп кенә ялкынлы лирик шигырьләр, поэмалар тудырды. Шагыйрь шулай ук проза һәм драма әсәрләре дә язды.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, ул фашизмга каршы сугышка китә һәм 1945 елны Көнчыгыш Пруссиядәге сугышларда батырларча һәлак була.

**Хабибуллин Рифнур** «Ант» шигырен укый.

**1а.б.** Татар поэзиясенең популяр шагыйрьләреннән берсе Нур Галим улы Баянов Татарстанның Актаныш районы Әнәк авылында туа. Октябрьга кадәр иске мәктәп-мәдрәсәләрдә, революциядән соң педагогик курсларда, Казанда хәрби
мәктәптә укый, Кызыл Армия сафында хезмәт итә. Нур Баян матбугатка 1925 елда чыга. Аның лирик шигырьләре һәм поэмалары «Яңгырлы төн» (1933), «Шигырьләр һәм поэмалар» (1934), «Гөләндәм» (1940), «Туган авыл» (1941) һ.б. исемнәрдә егермегә якын китап булып басылып чыкты.

**Зиятдинова Зөбәрҗәт:** «Санитарка» шигырен укый.

**2 а.б.** Абдулла Бари улы Алишев 1908 елда Татарстанның Куйбышев районы Көек авылында туа. Башта җидееллык мәктәпне, аннары Казан җир төзелеше техникумын тәмамлый.

Озак еллар «Техника», «Пионер каләме» журналларында җаваплы секретарь булып эшли.

А.Алиш балалар өчен күп әсәрләр язды. Аның кечкенә күләмле әкиятләрен балалар бик яратып укыйлар. «Әкиятләр» китабы инде дистәгә якын басмада чыгарылды. Шулай ук язучының сәхнә әсәрләре, шигырьләре һәм балалар тормышыннан алып язылган очерклары бар.

1941 елда А.Алиш Бөек Ватан сугышына китә. 1941 елның октябрендә Брянск шәһәре янында, Десна елгасы буенда, каты сугышларның берсендә дошман кулына эләгә. А.Алиш концлагерьларда чакта да соңгы сулышына кадәр Ватанга, халкына тугрылыклы булып калды. Ул тоткынлыкта, Муса Җәлил белән берлектә, фашизмга каршы көрәш алып бара, явыз дошманга нәфрәт белдереп шигырьләр яза. 1944 елның августында фашистлар А.Алишны җәзалап үтерәләр.

**Сафиуллина Лилия башкаруында Абдулла Алиш сүзләренә язылган җыр “Кыр казлары”**

**1 а.б.** Рахман Ильяс (Габдрахман Вәкил улы Ильясов) 1908 елда Татарстан Республикасы Кайбыч районы Карамасар авылында туа.

1919 елның җәендә Рахман Ильяслар гаиләсе Кавказга күчеп китә. Анда алар Грозный нефть промыселларында эшлиләр.

Рахман Ильяс 1933 елда Казанга килә һәм зур дәрт белән әдәби эшкә керешә. 1934-1935 елларда аның «Өндәр карт», «Таулар арасында» дигән китаплары басылып чыга.

Язучының иҗаты эшчеләр тематикасын чагылдыруы белән характерлы. Ул нефть чыгаручылар тормышын яхшы белә. Озак һәм күп көч куеп эшләү нәтиҗәсендә язучы нефтьчеләр тормышыннан «Горизонт» дигән зур күләмле әсәр яза. Бу әсәр укучылар тарафыннан яратып укыла һәм берничә тапкыр басылып чыга. Рахман Ильяс 1938 елда «Фонтан» исемле драма яза. Шулай ук «Зәйнүш дускай», «Танышлар» дигән әсәрләрен язып, бастырып чыгара.

Бөек Ватан сугышы башлангач, ул үзе теләп фронтка китә һәм рота командиры буларак каты сугышларда катнаша. Рахман Ильяс 1943 елның 23 августында батырларча һәлак була.

«Партизаннар» әсәреннән өзек карап китегез.**(Габделхаков, Шәрипов, Газимҗанова Г.)**

«Урман буеннан фашистларның кавалерия отряды үтеп бара иде. Немецлар юлда иң яшь партизан Ваняны күрделәр.

Фашист унтеры:

– Тукта! Дөресен әйт, син коммунистмы? - дип кычкырды.

Зәңгәр күзле малай:

– Юк, пан, юк, юк, – дип җавап кайтарды.

Унтер, рус телен боза-боза, сорау алуында дәвам итте:

– Әтиең кем?

– Әтием күптән үлде, мин энем белән генә калдым. Урман каравылчысы булып эшлим, әнә тегендә торам, – дип, ул урман ягына таба төртеп күрсәтте.

– Ә шәһәргә таба бара торган юлны белмисеңме?

– Ник белмәскә! Яхшы беләм...

Унтер:

– Шәһәргә алып бар безне, – дип боерык бирде, – әгәр алдасаң, менә нәрсә алырсың, – дип өстәде һәм револьверын селкетеп куйды.

Ваня бандитларны урманның бормалы юлы буйлап ияртеп китте. Фашистлар сагайдылар. Унтер, Ваняны әледән-әле туктатып:

– Дөрес алып бармасаң, атып үтерәм, – диде.

Инде караңгылана башлады. Урман сирәгәйгәннән-сирәгәя бара. Куе урманны куаклыклар алмаштыра. Алда киң сызык булып баткак сазлыклар җәелеп ята.

– Хәзер, менә монда, – диде Ваня һәм баткаклык ягына төртеп күрсәтте.

Нәкъ шул вакыт партизаннарның ату тавышлары күтәрелде. Пулемет тырылдарга тотынды. Атлар куркынып төрле якка ташландылар һәм сазлыкка кереп баттылар. Фашист унтеры юл күрсәтүченең кем булуын хәзер генә аңлады. Ләкин соң иде инде. Ату көчәйгәннән-көчәя барды.

Урман авызында:

– Үлем фашистларга! – дигән көчле тавышлар яңгырады».

**1 а.б**. Демьян Фәтхи (Касыйм Фәтхетдинов) 1906 елда Ульяновск өлкәсенең Чардаклы районы Татар Колмаеры авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Башта үз авылларында укый, аннан соң Самарадагы Татар-башкорт педагогия техникумына укырга керә. Техникумда укыган елларында шигырьләр яза башлый. 1926 елда Демьян Фәтхи Казанга килә һәм Татрабфакта укый, бер үк вакытта газета редакцияләрендә дә эшли.

1929 елда шагыйрьнең «Тальян» исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөньяга чыга. Озак та үтми, Мәскәүдә «Металл тавышлары» исемле икенче китабы басыла. Ул барлыгы 6 китап чыгара.

Бөек Ватан сугышы башлану белән Демьян Фәтхи, кулына корал алып, фронтка китә. Дошманнарга көчле нәфрәт белдергән шигырьләр язып, фронт газеталарында бастыра.

Демьян Фәтхи 1942 елда Сталинград сугышларында катнаша һәм яралана. Яралары төзәлгәч, яңадан алгы сафка баса, Сталинград каһарманнары турында поэма яза башлый, ләкин аны төгәлли алмый кала.

Тормышны өзелеп сөюче, бай хыяллар белән яшәүче талантлы шагыйрь-солдат 1943 елда Кантемирово янында барган сугышта каты яраланып һәлак була.

**Гайнетдинов Илгизәр:** «Атыш тынган минутларда» шигырен укый.

**2 а.б.** Хәбра Рахман (Хәбибрахман Габдрахманов) 1914 елда Татарстанның Балтач районы Яңгыл авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Кечкенәдән ятим кала, ике сеңлесен һәм энесен тәрбияләү аның өстенә төшә, яшьләй кулакларда төрле эшләр эшли.

1930 елда Арча мәктәбенең 7 классын төгәлли һәм кыска сроклы курсларда укып укытучы була. Башта Саба районы Курсабаш мәктәбендә, аннары Курсада эшли. Шушы елларда «Ялчы» газетасында кыска хикәяләре һәм шигырьләре басыла.

1931-1932 уку елында Казандагы Татрабфакны тәмамлап, пединститутка укырга керә.

Хәбра Рахман 1936 елда педагогия институтын бик яхшыга тәмамлый, татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып Алабуга педучилищесына китә. Анда вакытта татар халык иҗатын җыю өстендә эшли.

1937 елны яшь шагыйрьнең «Чәчәк ява» исемле беренче шигырьләр китабы басылып чыга.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, Хәбра Рахман сугышка китә. Мәскәү янында барган сугышларда яралана һәм 1942 елның ноябрендә батырларча һәлак була.

**Бектурсунов Наил :** «Сугышта» әсәреннән өзек укый.

«Шәрипов прикладсыз винтовкасын агачлар арасына ыргытты һәм егылып җитүен дә көтмәстән, тегенең кулыннан мылтыгын тартып алды да яңадан вак агачлар төркеме артына сикерде. Кинәт ату тавышы ишетелде, сул колак яныннан каты сызгырып һәм колак яфракларын көйдереп пуля үтеп китте. Чигә буйлап, муенга таба ниндидер җылы, йомшак һәм юеш нәрсә шуып төшә башлады. Шәрипов тиз генә як-ягына карап алды. Каршыдан аңа таба маузерын төзәгән, ачудан тагын да ныграк кара янган офицер һәм аннан аз гына артта, мылтыгын алга сузып, петлицаларына икешәр сары йолдыз кадаган бер япон солдаты килә иде. Шәрипов, агачлар артына яшеренеп, мылтыгын офицерга төзәде. Шулчак сул яктан көчле, калын тавыш ишетелде:

— Ташла маузерыңны, кулларыңны күтәр!».

**1 а.б.** Ә хәзер авылдаш шагыйребез Хәбра Рахманның якты истәлегенә багышлап җырлый **Сәләхетдинова Эльвина “Билгесез солдат”**

**2 а.б.** Кәшфи Басыйр улы Басыйров 1906 елда Башкортстанның Бәләбәй районы Мәтәүбаш авылында туа. Кәшфи бик зирәк малай була һәм башлангыч мәктәпне мактау кәгазе белән тәмамлый.

Бәләбәй педагогия техникумында укыган елларында К.Басыйров сабакташлары Гази Кашшаф, Фатих Кәримнәр белән бергә әдәби түгәрәк каршында кульязма журнал чыгара. Шул елларда авыл һәм укучылар тормышыннан алып, Кәшфи дә кыска хикәяләр яза.

Техникумны тәмамлаганнан соң, К.Басыйров авылга укытучы булып китә. 1934 елны Казанга килә, Татгосиздатта тәрҗемәче һәм редактор булып эшли.

1927 елда «Безнең юл» журналында К.Басыйровның «Минем сөюем» исемле хикәясе басылып чыга һәм укучылар тарафыннан уңай бәя ала. Язучы үзенең хикәяләрен «Совет әдәбияты», «Азат хатын», «Чаян» журналларында бастыра.

К.Басыйров зур күләмле әсәр язу өстендә эшли. Ләкин вакытсыз үлем аның хыялларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирмәде. Ул 1943 елның 16 гыйнварында фашистларга каршы кан коюлы сугышта һәлак булды.

Бөек Ватан сугышыннан соң язучының «Танышлар» дигән китабы басылып чыкты.

**Ахмадуллина Альбина:** «**Секретарь**» әсәреннән өзек укый. _

«Эш сәгате үткән. Йомышларын үтәргә килүче кешеләр дә юк. Канцеляриянең эшләнәсе эшләре дә тәмам булган, хәтта барлык әйберләр дә җыеп куелган иде. Шулай да Гали утыра бирде. Ул башта әле генә үзе җыештырган үз бүлмәсендәге әйберләрнең: рәсемнәрнең, плакатларның, игъланнарның, шкафларның урнашу рәвешен караштырды. Аларның кайберсен яңадан барып төзәтте, сыпырып-сыпырып алды. Ә соңыннан, һәммәсе тәмам булгач, ишеккә табарак китте дә инде бүлмәдәге әйберләрнең урынлы тору-тормауларын тикшереп түгел, ә бүлмәнең җыйнаклыгына, күңелгә ягымлылыгына рәхәтләнеп, рәхәткә чумып, басып торды. Стеналар елмайдылар. Гали үзе дә көлеп куйды. Ул, арлы-бирле йөренеп, инде күптән үк кайтып киткән председатель белән телефоннан сөйләшеп алды. Аннан соң стена буендагы диванга барып утырды».

**1 а.б.** Хәйретдинов Мөҗәһит Хәйретдин улы 1901 елда туа. Яшьтән үк әдәбият белән кызыксына, үзе дә шигырьләр яза һәм аларны район газеталарында бастырып чыгара.

Х.Мөҗәй гомеренең күп өлешен армия сафларында үткәрә. Ул 1931-1933 елларда Урта Азиядә, взвод командиры буларак, басмачыларга һәм кулак бандаларына каршы көрәштә катнаша. Бу елларда ул күп яза, шигырьләре, очерклары һәм хикәяләре газета-журналларда, альманахларда әледән-әле басылып тора. Менә шул вакытта Х.Мөҗәй Татарстанда үткәрелгән әдәби ярышта катнаша һәм беренче бүләкне ала.

1932 елда аның «Мылтыклылар» дигән китабы басылып чыга.

Х.Мөҗәй Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк алгы сызыкка баса, полковник дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Фронт газетасында аның батырлыклары турында язып чыгалар. Алгы сызыкта да Х.Мөҗәй язучылык эшен дәвам итә. Ул фронт хикәяләре, сугышчыларның батырлыкларын күрсәткән очерклар, шигырьләр яза. Аларның күбесе «Совет әдәбияты» журналында басыла.

Х.Мөҗәй 1944 елның 4 сентябрендә фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелә.

**Муллагалиева Алинә :** «Пулемет һәм кыз» шигырен укый.

**1 а.б.** Ә хәзер сүзне **Шәрипова Гөлгенәгә** бирәбез "Каның, җаның белән түләрсең"

**2 а.б.** Мөсәгыйть Мостафин 1909 елның 25 сентябрендә Ютазы районы Бәйрәкә авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Кечкенәдән әнисеннән ятим кала. 1927 елда Бәйрәкә мәктәбенең җиде классын тәмамлап, Казанга килә, рабфакта укый.

Аның беренче хикәяләре Ютазы районы газетасында басыла. 1931 елда беренче китабы — «Очрашу» исемле хикәяләр җыентыгы – дөньяга чыга. 1932 елда аның «Тыңлыйсыңмы, кордаш?» дигән икенче китабы басылып чыга. Шул ук елны балалар өчен «Үсү» җыентыгы басыла.

1931 елда Мостафин «Кызыл яшьләр» газетасында эшли һәм шул ук елның көзендә Ленинград тарих-лингвистика институтына укырга китә.

1941 елның 8 августында үзе теләп Бөек Ватан сугышына китә һәм анда артиллерия командиры булып катнаша. Фронтта вакытта язу эшен дәвам итә, фронт тормышын чагылдырган хикәяләрен бастыра. Ләкин талантлы язучының гомере вакытсыз киселә, ул 1941 елның 6 декабрендә һәлак була.

**Зәкиев Рафил :** «**Кызару**» әсәреннән өзек укый.

«Без Ногман белән бервакытны, аңа костюм сайлау өчен, Казандагы «ТУМ» магазинына кердек. Без мөрәҗәгать иткән сатучы яшь кенә бер хатын иде. Ул бик ачык кеше булып чыкты. Сораган бер сүзгә, җанны рәхәтләндерерлек итеп, тулы җавап биреп тора. Башка кайбер сатучылар кебек, үзенең кырыслыгы белән җанны биздерми. Ногманга бу җитә калды. Үзенә яраклы үлчәүдәге костюм юклыгын белгәч тә чыгып китәсе урында, Ногманым һаман сүз озайта бит. «Сездә йон костюмнар булгалыймы? Тагын кайчанрак кереп чыгарга мөмкин? Бу арада берәр нәрсә көтмисезме? Үзегез

күптән эшлисезме биредә? Монда башка иптәш була торган иде...», фәлән дә фәсмәтән, имеш. Товар караучылар янына кысылып, прилавка өстенә үк ята башлады бу. Мин аның җиңеннән тартып карасам да, ул миңа күз генә кысты: «Тукта әле!» имеш. Мин эчемнән генә: «Әйдә, рәхәтлән инде алай булгач», — дидем дә башка бүлеккә кереп киттем».

**1 а.б.** Мансур Гаяз улы Гаязов 1917 елда Мари Республикасының Бәрәңге районы Бәрәңге авылында туа.

Җиде классны тәмамлаганнан соң Бәрәңге педагогия училищесына укырга керә, училище каршындагы әдәбият түгәрәген җитәкли.

М.Гаяз җырга оста була, үзе язган шигырьләрне халык көйләренә салып, бик яратып җырлый. Аны авылдашлары һәм сабакташлары «оста җырлый иде», «тавышы матур һәм аһәңле иде», дип, сагынып телгә алалар.

Бөек Ватан сугышы елларында шагыйрь дошманнарга каршы каләм белән дә, корал белән дә көрәште. Фронт газеталарында аның ялкынлы шигырьләре басылып килде.

Ләкин яшь талант М.Гаяз Җиңү кояшының балкуын күрә алмады. Кара күзле, чандыр гәүдәле, түгәрәк йөзле, нечкә хисле 26 яшьлек батыр солдат үз Ватанына турылыклы булып, актык тамчы канына кадәр дошманнарга каршы сугышып, 1943 елның 19 ноябрендә Белоруссиядә, Витебск өлкәсендәге Ускорово авылы янында, каты сугыш барган вакытта һәлак булды.

Шагыйрьнең «Шигырьләр» дигән китабы 1959 елда басылып чыкты.

**Касимова Лилия:** «Түләтербез» шигырен укый.

**2 а.б.** Әгъзам Камал 1918 елда Татарстанның Апас районы Үтәмеш авылында туа.

1931-1934 елларда Әгъзам җидееллык мәктәптә укый. Мәктәпнең әдәби түгәрәгендә актив катнаша, «Яшь каләмнәр» дигән кулъязма журналның редакторы була. Бу журналда аның дистәләгән шигырьләре, җырлары урнаштырыла.

1934 елның җәендә яшь шагыйрь Казанга килә, финанс-экономика техникумына укырга керә. Ул Язучылар союзының шагыйрьләр секциясенә актив йөри, өлкән шагыйрьләрдән һәм язучылардан киңәшләр ала. «Җилфердә, байрак» исемле беренче шигырьләр җыентыгы 1938 елда дөнья күрә.

Техникумны уңышлы тәмамлаганнан соң, яшь шагыйрь газета редакцияләрендә эшли.

1939 елда Әгъзам Камалның икенче җыентыгы — «Һәйкәл янында җыр» дигән китабы – басылып чыга.

1939 елның көзендә Әгъзам армия сафларына алына. Салкын окопларда, землянкаларда яткан чакта да шигырь язудан туктамый.

Немец-фашистларга каршы барган каты сугышларның берсендә яраланып, госпитальгә керә. Сәламәтлеге начар булу сәбәпле, аңа фронтка — ут сызыгына барырга туры килми. Әгъзам Камалны Саратов шәһәрендәге хәрби училищега җибәрәләр. Анда укып офицер дәрәҗәсе алганнан соң, яңадан частена — Сталинград фронтына китә.

Әгъзам Камал 1943 елның 10 мартында фашистларга каршы атака вакытында һәлак була.

**Зиннәтуллина Алинә :** «Онытма» шигырен укый.

**2 а.б.** Хәмит Кави 1906 елда Чуашстан Республикасының Козловка районы Әлмән авылында укытучы гаиләсендә туа. 1920-1926 елларда Казан педтехникумында, 1926-1931 елларда Көнчыгыш techинститутының биология бүлегендә читтән торып укый. 1926 елдан Казан мәктәпләрендә, техникумнарында биология һәм география фәннәре укыта, бер үк вакытта әдәби-фәнни хезмәт белән дә шөгыльләнә.

Хәмит Кави ел саен илебезнең төрле почмакларына сәяхәт ясый. Ул бик яшьтән тарихи урыннар белән кызыксына, казылма байлыклар чыга торган урыннарда була һәм шулар турында очерклар, мажаралы хикәяләр яза.

Яшь язучының 1930 елда «Кавказ таулары аркылы җәяү» дигән китабы басылып чыга.

Х.Кави барлыгы уннан артык китап чыгара. Шулар арасында «Идел буенда йөрү», «Кузбасска сәяхәт», «Сәяхәт» һәм башка китаплары бар.

1941 елның сентябрендә Хәмит Кави армия сафларына алына һәм лейтенант булып хезмәт итә. Фронтта да үзенең иҗат эшен туктатмый. «Сугыш сәяхәте» дигән китап язу өчен материал туплый. «Туп һәм китап», «Хаккый батыр турында» исемле китаплар язарга да әзерләнүе билгеле. Әмма ул үзенең матур хыялларын тормышка ашыра алмый кала. 1944 елның 15 июлендә Хәмит Кави Волынск өлкәсе Друженополь янындагы сугышта батырларча һәлак була.

**Гарипова Гөлия:** «Кильдин атавы» әсәреннән өзек укый.

«Кооператив әйберләрен алырга килгән кеше кырыйга безне дә алып чыкты. Шушы төшү белән Кильдин атавында бер атна тордык. Килгән кешеләр мәктәп йортына урнашалар икән, без дә шунда кереп урнаштык. Мәктәпнең бер бүлмәсендә ике өстәл, бер карават бар иде. Караватка Соловьев, өстәлләргә Фиш белән мин урнаштык. Шулай итеп, тын гына тора башладык. Атау буйлап көне буе йөргәч, кичке унберләрдә кайтып мич ягып җибәрә идек. Мич янып кызгач кына, тагын утын салып, йокларга ята идек. Мич сәгать унда ягылды, сәгать уникеләрдә бүлмә тәмам кызу иде. Без сәгать икегә кадәр укып яттык. Яткан вакытта бүлмә җылы булса да, иртәнге сәгать сигезләрдә мин суыкка калтырап уянып киттем. Бу суыкта артык ятарга мөмкин булмагач, утын ярып тагын мичне ягып җибәрдек. Шуннан соң гына тагын йоклап китеп булды. Минем юрганым юка булганга күрә, ахрысы, суык миңа катырак тәэсир итә иде. Беренче көнне суыкның тәмен татыганга, икенче көнне кичке унда мичне ягып, йокларга ятканда да сүндермәдек».

**1 а.б.** Касыйм Мисбах улы Вахитов Башкортстанның Әлшәй районы Нигъмәтулла авылында 1916 елда туа. 1935 елда Башкортстан педагогия техникумында укый һәм аны тәмамлагач җидееллык мәктәптә физика-математика укытучысы булып эшли. Аннан соң Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә.

Касыйм Вахит техникумда укыган елларда шигырьләр яза башлый һәм аны өлкә газеталарында бастыра.

Касыйм Вахит «Кызыл Татарстан», «Яшь сталинчы» газеталарында һәм «Совет әдәбияты», «Чаян», «Азат хатын» журналларында актив языша. Аның шигырьләре «Дуслык», «Очкыннар» һәм «Бәхетле яшьләр» исемендәге альманахларда басыла.

1942 елның 4 октябрендә батырларча һәлак була.

**5кл. Закирова Алсу Зиннәтуллина Алинә** “Җиңеп кайт” җырын башкаралар

**1 а.б.** Мөхәммәт Әхмәтгалиев 1920 елның 24 гыйнварында Казан шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә. 1937 елда Яңа Бистәдәге 13 нче мәктәпнең 10 классын тәмамлый. Мәктәптә укыган елларында ук балалар өчен кыска-кыска шигырьләр яза. 1935 елда «Мин бәхетле» исемле беренче шигыре «Яшь ленинчы» газетасында басыла. Шул еллардан алып матбугатта системалы рәвештә шигырьләре белән катнаша башлый.

М.Әхмәтгалиев 1937 елда Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә. 1937-1941 елларда «Шат балалык», «Очкыннар», «Туган ил», «Чәчәк атабыз», «Алмаш» һәм «Бәхетле яшьләр» исемле альманахларда дистәләрчә шигырьләре басыла.

Бөек Ватан сугышы башлану белән М.Әхмәтгалиев сугышка китә. 1943 елның октябрендә батырларча һәлак була.

**Закирова Гөлүсә:** «18 яшь» шигырен укый.

**2 а.б.** Сөләйман Мөлекев 1920 елның 5 гыйнварында Балтач районы Пыжмара авылында туып үсә. Җидееллык мәктәпне һәм Алабуга китапханә техникумындагы

курсларны тәмамлаганнан соң, 1940 елга кадәр Татарстан авылларында китапханәче һәм укытучы булып эшли.

Сөләйман Мөлекев язган шигырьләрен Казанга, «Пионер каләме» редакциясенә җибәрә. Озак та үтми, аның бер шигырен бастыралар. Яшь авторның өлкә газеталарында, альманахларда, «Пионер каләме» журналында шигырьләре күренә башлый.

1940 елның 2 февралендә Армия сафларына алына һәм Көнбатыш Украинада чик сакчысы булып хезмәт итә. Бөек Ватан сугышының беренче көненнән үк немец-фашистларга каршы көрәшә. 1941 елның сентябрендә Киев өчен булган каты сугышларның берсендә һәлак була.

Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалган батырлар рухына багышлап **Хәбибуллин Руфил Әмирхан Еникинең "Кем җырлады?" әсәреннән өзек укый**

**2 а.б**. Безне сезне Бөек Ватан сугышында ятып калган татар язучыларының тормыш юллары һәм иҗатлары белән таныштырдык. Әйдәгез әле, аларны бер минут тынлык белән искә алыйк.

*(1минут тынлык)*

**1а.б.**

**70 ел илебез күге аяз!**
**Сугыш беркайчан да булмаска тиеш.**
**Я, әйтегез, сугыш кемгә кирәк икән?**
**Һәр адәмнең газиз башы бит бер генә,**
**Бу дөньяда безне сөеп кеше иткән**
**Якты, изге җәннәтебез – тик Җир генә!**

**2а.б**

**Кемгә кирәк кан-яшь кою**
**Кем тели сугыш-афәт**
**Юкка чыксын җир йөзеннән**
**Бары тынычлык булганда**
**Җирдә яшәве рәхәт.**

**1 а.б.**

**Үзгәрсә дә заман**
**Юк үзгәрми**
**Төсе уңмый җиңү сүзенең**
**Нәкъ 70 ел элек**
**Шундый ук яз**
**Җиңү алып килгән бу җиргә.**
**Сафлар сыек,**
**Җиңүчеләр китә**
**Кими тарих,**
**Йолдыз югала.**
**Мәңгелек моң булып**
**Хәтер кала,**
**Батырларның даны,**
**Җыр кала.**

**2 а.б.** Без кичәбезне 7нче сыйныф укучылары тәмамлый.

(Кичә тәмам.)

«Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил!

Мин шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып сап-салкын су эчәм. Әмма, күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.

Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил!

Сине сагынган саен миндә көч-дәрт арта, рухым канатлана. Чит илдә йөреп мин ачык аңладым: совет кешесе өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул.

Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем.

Сагындым, бик сагындым сине, изге Туган ил».

( Г.Кутуй “Сагыну”.)

**Укучы:** «Партизаннар» әсәреннән өзек укый.

«Урман буеннан фашистларның кавалерия отряды үтеп бара иде. Немецлар юлда иң яшь партизан Ваняны күрделәр.

Фашист унтеры:

– Тукта! Дөресен әйт, син коммунистмы? - дип кычкырды.

Зәңгәр күзле малай:

– Юк, пан, юк, юк, – дип җавап кайтарды.

Унтер, рус телен боза-боза, сорау алуында дәвам итте:

– Әтиең кем?

– Әтием күптән үлде, мин энем белән генә калдым. Урман каравылчысы булып эшлим, әнә тегендә торам, – дип, ул урман ягына таба төртеп күрсәтте.

– Ә шәһәргә таба бара торган юлны белмисеңме?

– Ник белмәскә! Яхшы беләм...

Унтер:

– Шәһәргә алып бар безне, – дип боерык бирде, – әгәр алдасаң, менә нәрсә алырсың, – дип өстәде һәм револьверын селкетеп куйды.

Ваня бандитларны урманның бормалы юлы буйлап ияртеп китте. Фашистлар сагайдылар. Унтер, Ваняны әледән-әле туктатып:

– Дөрес алып бармасаң, атып үтерәм, – диде.

Инде караңгылана башлады. Урман сирәгәйгәннән-сирәгәя бара. Куе урманны куаклыклар алмаштыра. Алда киң сызык булып баткак сазлыклар җәелеп ята.

– Хәзер, менә монда, – диде Ваня һәм баткаклык ягына төртеп күрсәтте.

Нәкъ шул вакыт партизаннарның ату тавышлары күтәрелде. Пулемет тырылдарга тотынды. Атлар куркынып төрле якка ташландылар һәм сазлыкка кереп баттылар. Фашист унтеры юл күрсәтүченең кем булуын хәзер генә аңлады. Ләкин соң иде инде. Ату көчәйгәннән-көчәя барды.

Урман авызында:

– Үлем фашистларга! – дигән көчле тавышлар яңгырады».

( Рахман Ильяс” Партизаннар”.)

**Укучы:** «Сугышта» әсәреннән өзек укый.

«Шәрипов прикладсыз винтовкасын агачлар арасына ыргытты һәм егылып җитүен дә көтмәстән, тегенең кулыннан мылтыгын тартып алды да яңадан вак агачлар төркеме артына сикерде. Кинәт ату тавышы ишетелде, сул колак яныннан каты сызгырып һәм колак яфракларын көйдереп пуля үтеп китте. Чигә буйлап, муенга таба нindидер җылы, йомшак һәм юеш нәрсә шуып төшә башлады. Шәрипов тиз генә як-ягына карап алды. Каршыдан аңа таба маузерын төзәгән, ачудан тагын да ныграк кара янган офицер һәм аннан аз гына артта, мылтыгын алга сузып, петлицаларына икешәр сары йолдыз кадаган бер япон солдаты килә иде. Шәрипов, агачлар артына яшеренеп, мылтыгын офицерга төзәде. Шулчак сул яктан көчле, калын тавыш ишетелде:

— Ташла маузерыңны, кулларыңны күтәр!».

( Хәбра  Рахман “Сугышта”.)

**Укучы:** «Секретарь» әсәреннән өзек укый. _

«Эш сәгате үткән. Йомышларын үтәргә килүче кешеләр дә юк. Канцеляриянең эшләнәсе эшләре дә тәмам булган, хәтта барлык әйберләр дә җыеп куелган иде. Шулай да Гали утыра бирде. Ул башта әле генә үзе җыештырган үз бүлмәсендәге әйберләрнең: рәсемнәрнең, плакатларның, игъланнарның, шкафларның урнашу рәвешен караштырды. Аларның кайберсен яңадан барып төзәтте, сыпырып-сыпырып алды. Ә соңыннан, һәммәсе тәмам булгач, ишеккә табарак китте дә инде бүлмәдәге әйберләрнең урынлы тору-тормауларын тикшереп түгел, ә бүлмәнең җыйнаклыгына, күңелгә ягымлылыгына рәхәтләнеп, рәхәткә чумып, басып торды. Стеналар елмайдылар. Гали үзе дә көлеп куйды. Ул, арлы-бирле йөренеп, инде күптән үк кайтып киткән председатель белән телефоннан сөйләшеп алды. Аннан соң стена буендагы диванга барып утырды».

( Кәшфи Басыйров “ Секретарь”.)

**Укучы:** «Кызару» әсәреннән өзек укый.

«Без Ногман белән бервакытны, аңа костюм сайлау өчен, Казандагы «ТУМ» магазинына кердек. Без мөрәҗәгать иткән сатучы яшь кенә бер хатын иде. Ул бик ачык кеше булып чыкты. Сораган бер сүзгә, җанны рәхәтләндерерлек итеп, тулы җавап биреп тора. Башка кайбер сатучылар кебек, үзенең кырыслыгы белән җанны биздерми. Ногманга бу җитә калды. Үзенә яраклы үлчәүдәге костюм юклыгын белгәч тә чыгып китәсе урында, Ногманым һаман сүз озайта бит. «Сездә йон костюмнар булгалыймы? Тагын кайчанрак кереп чыгарга мөмкин? Бу арада берәр нәрсә көтмисезме? Үзегез күптән эшлисезме биредә? Монда башка иптәш була торган иде...», фәлән дә фәсмәтән, имеш. Товар караучылар янына кысылып, прилавка өстенә үк ята башлады бу. Мин аның җиңеннән тартып карасам да, ул миңа күз генә кысты: «Тукта әле!» имеш. Мин эчемнән генә: «Әйдә, рәхәтлән инде алай булгач», — дидем дә башка бүлеккә кереп киттем».

( Мөсәгыйть Мостафин « Кызару».)

**Укучы:** «Мигуель» әсәреннән өзек укый.

«Балалар Мигуельнең сөйләвен тыңларга әзерләнделәр. Аларның һәркайсы Мигуель тирәсенәрәк урнашырга тырышты. Мигуель, иптәшләрен бераз шаяртып алырга теләп, диваннан торды да чыбыктан үрелгән дуга табанлы креслога күчеп утырды. Балалар, кинәт дулкынланган диңгез өсте шикелле кайнашып, җанлы кыршау ясап, Мигуельне әйләндереп алдылар».

( Әхмәт Гыймадов” Мигуель».)

**Укучы:** «Кильдин атавы» әсәреннән өзек укый.

«Кооператив әйберләрен алырга килгән кеше кырыйга безне дә алып чыкты. Шушы төшү белән Кильдин атавында бер атна тордык. Килгән кешеләр мәктәп йортына урнашалар икән, без дә шунда кереп урнаштык. Мәктәпнең бер бүлмәсендә ике өстәл, бер карават бар иде. Караватка Соловьев, өстәлләргә Фиш белән мин урнаштык. Шулай итеп, тын гына тора башладык. Атау буйлап көне буе йөргәч, кичке унберләрдә кайтып мич ягып җибәрә идек. Мич янып кызгач кына, тагын утын салып, йокларга ята идек. Мич сәгать унда ягылды, сәгать уникеләрдә бүлмә тәмам кызу иде. Без сәгать икегә кадәр укып яттык. Яткан вакытта бүлмә җылы булса да, иртәнге сәгать сигезләрдә мин суыкка калтырап уянып киттем. Бу суыкта артык ятарга мөмкин булмагач, утын ярып тагын мичне ягып җибәрдек. Шуннан соң гына тагын йоклап китеп булды. Минем юрганым юка булганга күрә, ахрысы, суык миңа катырак тәэсир итә иде. Беренче көнне суыкның тәмен татыганга, икенче көнне кичке унда мичне ягып, йокларга ятканда да сүндермәдек».

( Хәмит Кави “Кильдин атавы”.)